**Бакчага йөрмәүчеләр өчен үзәк ачтык.**

Яр Чаллының 95нче “Балкыш” балалар бакчасында балалар бакчасына йөрмәүче нәниләр өчен“ПРОФЕССИЯ – АТА-АНАЛАР!” консультация үзәге эшли башлады.

Үзәккә килүче балалар һәм ата-аналар аерым ишектән кереп өс киемнәрен алыштыралар да балалар бакчасы буйлап сәяхәткә чыгалар.Психолог Олеся Владимир кызы Шагиева кечкенә нәниләр әти-әниләре белән төрле формада иҗади эшчәнлекләрен арттыралар, рәсем ясыйлар, буйыйлар. Музыка җитәкчеләре Татьяна Сергей кызы Солёнова, Дария Гакил кызы Яруллина ярдәмендә җырлыйлар, бииләр, артистлык осталыкларын ачалар. Логопед Ольга Николай кызы Песигина белән сөйләм телен үстерү өчен төрле күнегүләр ясыйлар. Без, балаларга татар телен өйрәтүче тәрбиячеләр Миләүшә Наил кызы Рамазановаһәм мин Гөлсөяр Рәис кызы Әмирова балалар белән дидактик, милли уеннар уйныйбыз, өстәл, бармак театрлары күрсәтәбез. Спортинструктор Дания Мәбәрәк кызы Тимошкина белән хәрәкәтле уеннар башкаралар. Ата-аналар бакча мөдире, консультация үзәге җитәкчесе Екатерина Хөсни кызы Яруллинабелән очрашып үзләрен кызыксындырган сорауларга җавап табалар.

*Гөлсөяр Әмирова,*

*Чаллы шәһәре, 95нче балалар бакчасы тәрбиячесе.*